КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Республиканское агентство по печати
и массовым коммуникациям
Декабристов ул., 2, г.Казань, 420066

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ
Республика матбугат һәм массакүләм
коммуникацияләр агентлыгы
Декабристлар ур., 2, Казан шәһәре, 420066

Тел.: (843)570-31-22, факс:(843)537-91-04, ra.tatmedia@tatar.ru, tatmedia.tatarstan.ru

ПРИКАЗ БОЕРЫК

2020 елның 18 феврале, № 7-п

Интернет массакүләм мәгълүмат чаралары
өчен республика журналистлар конкурсын
үткәрү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 25 октябрендәге 794 номерлы карары белән расланган “2014 – 2022 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү” дәүләт программасын гамәлгә ашыру кысаларында боерык бирәм:

1. 2020 елның 1 апреленнән 1 сентябренә кадәр Интернет массакүләм мәгълүмат чаралары өчен республика журналистлар конкурсын оештырырга һәм үткәрергә.

2. 2020 елда Интернет массакүләм мәгълүмат чаралары өчен республика журналистлар конкурсы турында кушымта итеп бирелә торган Нигезләмәне расларга.

3. “Татмедиа” республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының “Интернет массакүләм мәгълүмат чаралары өчен республика журналистлар конкурсын оештыру турында” 2019 елның 28 мартындагы 32-п номерлы боерыгын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны җитәкче урынбасары И.Ф.Миргалимовка йөкләргә.

Җитәкче А.С.Сәлимгәрәев

“Татмедиа” республика
матбугат һәм массакүләм
коммуникацияләр агентлыгы
җитәкчесенең
2020 елның 18 февралендәге 7-п
номерлы боерыгы белән
РАСЛАНДЫ

**Интернет массакүләм мәгълүмат чаралары өчен**

**республика журналистлар конкурсын үткәрү турында**

# НИГЕЗЛӘМӘ

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Интернет массакүләм мәгълүмат чаралары өчен республика журналистлар конкурсы (алга таба – Конкурс) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 25 октябрендәге 794 номерлы карары белән расланган “2014 – 2022 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү” дәүләт программасы кысаларында үткәрелә.

1.2. Конкурсның оештыручысы – “Татмедиа” республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы (алга таба – Агентлык);

1.3. Конкурс 2020 елның 1 апреленнән 1 сентябренә кадәр үткәрелә. Конкурс үткәрү тәртибе, сроклары, шартлары һәм конкурс эшләрен бәяләү критерийлары турында мәгълүмат Оештыручының рәсми сайтында (http://tatmedia.tatarstan.ru) “Яңалыклар”, “Конкурслар” бүлекләрендә урнаштырыла.

## 2. Конкурсның максаты

2.1. Конкурсның максаты – Интернет челтәрендә проектларны гамәлгә ашыручы журналистларны һәм массакүләм мәгълүмат чараларын барлау һәм бүләкләү.

## 3. Нигезләмәдә кулланыла торган төп төшенчәләр

Интернет массакүләм мәгълүмат чаралары – челтәр басма, басма вакытлы матбугатның, телеканалның, радиоканалның, телепрограмманың,

радиопрограмманың, видеопрограмманың, кино хроникасы программасының, даими исем белән тарала торган башка массакүләм мәгълүматның интернет версиясе һәм/яисә аларның социаль челтәрләрдәге проектлары.

Гариза бирүче – Конкурс турында нигезләмәнең 6 пункты нигезендә документлар тапшырган массакүләм мәгълүмат чаралары (законнарда билгеләнгән тәртиптә теркәлгән) редакцияләре.

Катнашучы – тапшырылган эшләре Конкурста катнашырга рөхсәт ителгән ММЧ (законнарда билгеләнгән тәртиптә теркәлгән) редакцияләре.

Конкурс комиссиясе – Интернет массакүләм мәгълүмат чараларын бәяләүче затлар төркеме.

Конкурста җиңүче –призлы урын алган катнашучы.

## 4. Конкурста катнашучылар

4.1. Конкурста катнашу өчен гариза бирүчеләр әлеге Нигезләмәнең 5 бүлегендә бәян ителгән тәртиптә һәм шартларны үтәп документлар әзерләргә һәм тапшырырга тиеш;

4.2. Гариза биргән Интернет массакүләм мәгълүмат чарасын Конкурска кертү турындагы карарны катнашучының гаризаны Нигезләмәдә күрсәтелгән таләпләр нигезендә һәм срокларда тапшыру шартын үтәве нигезендә кабул ителә.

## 5. Конкурсны үткәрү шартлары һәм тәртибе

5.1. Конкурска гаризалар кабул итү: 2020 елның 1 апреленнән.

Гаризалар кабул итү тәмамлану: 2020 елның 1 сентябре (әлеге датаны кертеп).

Оештыручының рәсми сайтында Конкурс нәтиҗәләре турында мәгълүмат урнаштыру: 2020 елның 1 октябреннән дә соңга калмыйча.

Конкурста җиңүчеләрне һәм призерларны бүләкләү: мәгълүмат Оештыручының рәсми сайтында “Конкурслар һәм проектлар” бүлегендә урнаштырыла;

5.2. Гариза бирүчеләрдән конкурста катнашу өчен түбәндәге документлар кабул ителә:

1) катнашу өчен Анкета-гариза (1 нче кушымта) (төп нөсхә, күчермә яисә сканер аша чыгарылган PDF-файл форматындагы вариант);

2) Интернет массакүләм мәгълүмат чаралары битләренә актив сылтамалар һәм скриншотлар;

3) юридик зат буларак теркәлгән массакүләм мәгълүмат чарасы редакцияләре өчен:

юридик затны салым органында исәпкә кую турында таныклык (ИНН) (күчермәсе);

юридик затны дәүләт теркәве турында таныклык (Төп дәүләт теркәү номеры, булган очракта) (күчермәсе);

юридик зат җитәкчесен вазыйфага билгеләп кую турында боерык (күчермәсе);

редакция уставы (күчермәсе);

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (Конкурска документлар тапшырган көнгә кадәр иң күбе алты ай алдан бирелгән);

ММЧ теркәү турында таныклык яисә Теркәлгән массакүләм мәгълүмат чаралары реестрыннан өземтә (күчермәсе);

персональ белешмәләрне эшкәртүгә ризалык (2 нче кушымта)

4) юридик зат булмаган массакүләм мәгълүмат чарасы редакцияләре өчен:

ММЧ теркәү турында таныклык яисә Теркәлгән массакүләм мәгълүмат чаралары реестрыннан өземтә (күчермәсе);

массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясе уставы яисә, массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясендә кимендә 10 кеше эшләсә, "Массакүләм мәгълүмат чаралары турында" 1991 елның 27 декабрендәге 2124-I номерлы Россия Федерациясе Законының (алга таба – ММЧ турында Закон) 20 статьясы нигезендә аны алмаштыра торган шартнамә;

баш мөхәррирне вазыйфага билгеләп кую турында документның күчермәсе.

персональ белешмәләрне эшкәртүгә ризалык (2 нче кушымта)

5.3. Документлар түбәндәге адрес буенча кабул ителә: 420066, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт, “Татмедиа” матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгы, 6 кат, 5 кабинет, ММЧ бүлеге, “Теле барның юлы бар” (“Знание языка открывает возможности”) Интернет массакүләм мәгълүмат чаралары өчен республика журналистлар конкурсына” дигән тамга белән, тел.: 8 (843) 570-31-12. e-mail: internet-smi2019@mail.ru.Конкурска җибәрелеп тә, Нигезләмәдә күрсәтелгән датага алынмаган эшләр каралмый һәм кире кайтарыла.

5.4. Документлар пакетының тулы булмавы һәм Анкета-гаризаның әлеге Нигезләмәгә туры килмәве Конкурста катнашуга рөхсәт бирмәү өчен нигез булып тора.

5.5. Катнашучыга Конкурска кертелмәү турында хәбәр документларны алган мизгелдән алып 3 эш көне дәвамында Оештыручы җитәкчесе/җитәкче урынбасары имзалаган һәм анкета-гаризада күрсәтелгән адреска җибәрелгән заказлы рәсми хат белән хәбәр ителә.

5.6. Конкурста катнашуга бәйле чыгымнар (почта, командировка һ.б.) конкурста катнашучы тарафыннан мөстәкыйль түләнә.

5.7. Конкурс нәтиҗәләре 2020 елның 1 сентябреннән соңга калмыйча ясала һәм беркетмә рәвешендә рәсмиләштерелә, ул комиссия рәисе тарафыннан имзалана.

5.8. Конкурс шартлары буенча, тәкъдим ителгән эшләрне катнашучыларга кире кайтару, конкурста катнашучының эшне кире кайтару турындагы таләбе буенча гына, мондый таләп алынган мизгелдән алып 20 (егерме) календарь көн дәвамында гамәлгә ашырыла.

## 6. Конкурс эшләрен бәяләү критерийлары

6.1. Конкурс эшләрен бәяләгәндә сайтлар һәм социаль челтәрләр өчен түбәндәге критерийлар кулланыла:

- контент (контентның сыйфаты, һәрдаим яңартып тору, контентның кирәкле булуы) – (0-5 балл);
- статистика (“лайклар”, репостлар, язылучылар саны, бергәлекләрдә катнашучылар– (0-5 балл);
- стилистика (дизайн, материалны тәкъдим итү ысулы, стиль) – (0-5 балл).

6.2. Балларның призлы урыннар буенча бүленеше:

1 урын: 13-15 балл

2 урын: 12-13 балл

3 урын: 10-11 балл.

## 7. Конкурс комиссиясен оештыру һәм аның эшчәнлек тәртибе

7.1.Конкурс комиссиясе Конкурсны оештыручының боерыгы белән 5 кеше составында раслана һәм рәистән, конкурс комиссиясе әгъзаларыннан тора.

7.2. Конкурс комиссиясе үз эшен түләүсез башкара.

7.3. Конкурс комиссиясенең эше утырышларда гамәлгә ашырыла. Утырышта комиссия әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, утырыш тулы хокуклы дип танылa.

7.4. Конкурс эшенә рәис җитәкчелек итә. Комиссия рәисе булмаганда, рәис вазыйфалары ул билгеләгән урынбасарына йөкләнә.

7.5. Конкурс эшләрен әлеге Нигезләмәнең 6 бүлегендә билгеләнгән бәяләү критерийлары нигезендә Конкурс комиссиясенең һәр әгъзасы Интернет массакүләм мәгълүмат чаралары эшен (һәрбер критерий буенча) 5 баллы система буенча бәяли;

7.6. Конкурска өчттән кимрәк гариза тапшырылган булса, бер гариза да тапшырылмаса, тапшырылган гаризаларның берсе дә конкурс шартларына туры килмәсә, катнашкан эшләрнең берсе дә билгеләп үтәргә лаек дип танылмаса, Конкурс үткәрелмәгән дип танылa.

7.7. Иң күп балл җыйган катнашучы җиңүче дип танылa. Баллар саны тигез балган очракта призлы урын ике яки берничә катнашучыга бирелә. Бу очракта тиешле призлы урын өчен тәгаенләнгән акчалар җиңүчеләр арасында тигез итеп бүленә.

7.8.Конкурсны оештыручы оештыру-техник эшчәнлекне җайга салу, утырышны әзерләү һәм конкурс комиссиясе документациясен алып бару өчен җаваплы секретарь билгеләп куя.

7.9. Җаваплы секретарь конкурс комиссиясе составына керми һәм утырышларда тавыш бирү хокукыннан башка гына катнаша.

## 8. Финанс белән тәэмин итү

8.1. Конкурсны үткәрү чаралары Татарстан Республикасы бюджетыннан Программада каралган акчалар исәбенә финанслана;

8.2. Гомуми приз фонды 141 000 сум тәшкил итә;

8.3. Конкурста җиңүчеләр түбәндәге тәртиптә бүләкләнә:

I урын - 70 000 сум;

II урын - 35 500 сум;

III урын - 35 500 сум.

8.4. Акчалата призлар, редакция җиңүче дип игълан ителгәннән соң, Оештыручыга җибәрелгән хатта күрсәтелгән реквизитлар буенча, Конкурска йомгак ясау турында беркетмәгә имза салынган көннән алып 20 (егерме) эш көне эчендә исәп-хисап счетларына күчерү юлы белән тапшырыла.

## 9. Аерым шартлар

9.1.Оештыручылар түбәндәгеләргә хокуклы:

- әлеге Нигезләмәдә һәм Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарында билгеләнгән очраклардан, шулай ук бәхәсле очраклардан тыш, Конкурста катнашучылар белән язмача йә башка төрле элемтәләргә кермәскә;
- эшләрне тапшыру срогының беренче яртысында Россия Федерациясе законнары таләпләрен (РФ ГК 1058 ст.) үтәп, Конкурсны туктатырга яки әлеге Нигезләмәгә үзгәрешләр кертергә, бу хакта Агентлыкның рәсми сайтында (http://tatmedia.tatarstan.ru) “Яңалыклар” бүлегендә һәм Министрлыкның рәсми сайтында (http://mvd.tatarstan.ru) “Яңалыклар” бүлегендә тиешле мәгълүмат урнаштырып, Катнашучыларга хәбәр итәргә.

9.2. Конкурсның максатларын үзгәртүдән тыш, калган барлык шартларына үзгәрешләр кертелергә мөмкин.

Интернет массакүләм мәгълүмат чаралары өчен республика журналистлар конкурсын үткәрү турында нигезләмәѓә

1 нче кушымта

| **Конкурста катнашу өчен анкета-гариза** | |
|---|---|
| **Интернет ММЧ домен исеме** | |
| **Интернет ММЧ исеме** | |
| **Интернет ММЧ эчтәлеге** | |
| **Интернет ММЧ хуҗасының Ф.И.Ат ис.** | |
| **Интернет ММЧ хуҗасының электрон адресы** | |
| **Интернет ММЧ хуҗасының телефоны** | |
| **Комментарийлар – массакүләм мәгълүмат чарасын, аның бурычларын, укучылар категориясен тасвирлау** | |

______________________________________________________________________

**(Интернет ММЧ хуҗасының имзасы, имзаның тулы рәвеше;**

**мөһер, (булган очракта)**

Интернет массакүләм мәгълүмат чаралары өчен республика журналистлар конкурсын үткәрү турында нигезләмәгә

2 нче кушымта

**Персональ белешмәләрне эшкәртүгә ризалык**

Мин,____________________________________________________________

___, яшәү адресым___________________________________________

______________________________________________________________

__, шәхесне таныклаучы төп документым (паспорт)_____________________

____________________________________________________________

____________________________________, “Персональ белешмәләр турында” 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы нигезендә “Татмедиа” республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына (алга таба – оператор) (адресы: 420097, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 йорт) Интернет массакүләм мәгълүмат чаралары өчен республика журналистлар конкурсында катнашуга бәйле рәвештә үземнең персональ белешмәләрне эшкәртүгә, аларны җыюны, системалаштыруны, туплауны, саклауны, төгәлләштерүне (яңартуны, үзгәртүне), алардан файдалануны, аларны таратуны (шул исәптән башкаларга тапшыруны), үз исемемнән башка файдалануны, блокировать итүне, юкка чыгаруны да кертеп, ризалыгымны бирәм.

Эшкәртүгә ризалыгымны бирә торган персональ белешмәләрнең исемлеге:

| | |
|---|---|
| Эшкәртүгә ризалыгымны бирә торган персональ белешмәләрнең исемлеге: | (фамилия, исем, атасы исеме, җенес, туган көн һәм урын, гражданлык, шәхесне таныклаучы документның реквизитлары (документ төре, сериясе һәм номеры, кем тарафыннан бирелүе), яшәү урыны, теркәлү урыны, телефон номеры (шул исәптән кәрәзле телефон), электрон почта адресы, Россия Федерациясе кредит оешмасында ачылган исәп-хисап счеты турында белешмәләр) |

Әлеге ризалык имзаланган көннән алып 1 (бер) ел гамәлдә була.

Персональ белешмәләрнең субъекты үз персональ белешмәләрен эшкәртүгә әлеге ризалыкны, бу хакта операторга язмача хәбәр итеп, кире алырга хокуклы.

Персональ белешмәләрнең субъекты үз персональ белешмәләрен эшкәртүгә әлеге ризалыкны кире алган очракта оператор аларны эшкәртүне туктатырга яисә туктатуны тәэмин итәргә (персональ белешмәләрне эшкәртү оператор йөкләмәсе буенча башка затка тапшырылган булса) һәм, персональ белешмәләрне эшкәртү өчен аларны саклау башкача кирәк булмаса, ризалыкны кире алу турында мөрәҗәгать кергән көннән алып утыз көн эчендә персональ белешмәләрне юкка чыгарырга яисә юкка чыгаруны тәэмин итәргә (персональ белешмәләрне эшкәртү оператор йөкләмәсе буенча башка затка тапшырылган булса) тиеш. Күрсәтелгән вакыт эчендә персональ белешмәләрне юкка чыгару мөмкинлеге булмаган очракта, оператор аларны блокировать итә яисә блокировать итүне тәэмин итә (персональ белешмәләрне эшкәртү оператор йөкләмәсе буенча башка затка тапшырылган булса) һәм персональ белешмәләрне иң күп дигәндә алты ай эчендә юкка чыгара.

________________________________________________________/________________

(персональ белешмәләр субъектының Ф.И.Ат ис. һәм имзасы)

________________

(Дата)